Сәләт лагеренда җәйге ял

9 июньнән 26 июньгә кадәр уку- танып белү лагерьләрендә бернче смена булып узды. Анда безнең мәктәптән 15 укучы катнашты (5 – 10 класслар).

“Осталар Бистәсе” сменасы (инженерлык юнәлеше) Татарстан Республикасының Биләр бистәсендә урнашкан. Анда 10 укучы катнашты.

«Сэлэт Тел» сменасы (телләр үзләштерү) Татарстан Республикасының Лаеш районында урнашкан. Бу сменада 5 укучы катнашты.

Укучыларның фикерләре:

Бубекова Лилия (10 класс): «Дәресләр бик күңелле һәм кызыклы үтте. Укытучыларның осталыгы һәр балага якын килә белүе предметны тирәнтенүзләштерергә мөмкинлек бирде. Минем өчен Сәләт юнәлеш бирүче генә түгел, с яңа кешеләр белән аралашу. Әйдаманнарга зур рәхмәтнме җиткерәм.»

Бердникова Юлия (8А класс): «Сәләттә мин беренче тапкыр. Миңа бик ошады. Монда өйдәге кебек якын итәләр. Укытучыларыма, әйдаманнарыма зур рәхмәт. “Осталар бистәсе” сменасы минем гомеремнең иң матур мизгеле булып истә калачак.»

Валеева Камилә (эти-әниләр комитеты): «Сәләт лагеренә юл ачкан Мәктәп дирекциясенә зур рәхмәт. »

Ахатова Алсу (10 класс): “Сәләт”- бу искиткеч үзәк, анда һәркем үз талантын үстерә, кимчелекләрен бетерә ала. Монда һәркем сине аңлый. Мин быел “Осталар бистәсе”. Сменасында булдым. Бу сменада 9 яшьтән 17 яшькә кадәрге балалар, һәркемнең үз характеры, дөньяга үз карашы. Смена ахырында төркем зур бер гиаләгә әйләнде. Әйдаманнар безнең белән иртәдән кичкә кадәр 18 көн безнең белән булдылар. Аларга зур рәхмәтемне белдерәм. Мин сезне бик яратам. Дәресләр кызыклы узды. Миңа аеруча оригами дәресләре ошады. (воздушные змеи, самолеты, ракеты, светофор, светильник, спинеры, брелки, гидравлический кран). Әле без тагын роботларга программалар, төрле анимацияләр, төрле катлаулылыктагы санак уеннарына программалар төзедек. Мин укытучыларыма чиксез рәхмәтле. Сәләт – мин сине яратам.”

Салахова Диана (10 класс): “мин «Осталар бистәсе»ндә булдым. Мин шатлыгымны сүзләр белән генә әйтеп бетерә алмыйм. Гомергә истә калды. Киләчәктә Рухияттә һәм Эшмәкәрдә булырга телим. Сәләт – ул үзең булып калу дигән сүз.”

Демин Даниил (10 класс): “Миңа барысы ошады. Бигрәктә француз теле.”

Мухамадеева Миляуша һәм Васикова Камилә (6А класс): “без татарча, французча, алманча сөйләштек. Төрек һәм испан телләрен дә үзләштердек бераз. Кичке чаралар бигрәк тә ошады.”

Демина Даниила (әнисе): “ Зур рәхмәт! Гомумән алганда, бик бик шат, бик ошады балаларыбызга! “